**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**МУСЛЮМОВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**МУСЛЮМОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*№ 18* *«03» сентябрь 2025 ел*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын булдыру, аларның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» 2023 нче елның 14 нче апрель 5 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары белән расланган тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен пунктка туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын булдыру, аларның урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирү турында» 2023 нче елның 14 нче апрель 5 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урыны урнашуы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтына, районның җирле үзидарә органнары биналарындагы һәм авыл җирлекләрендәге мәгълүмат стендларына, әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасына урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка җиткерергә http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Мөслим авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **М.А.Байрханов**